**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Ленин пр.,17йорт,Актанышав.,423740

Тел.(85552)3-44-22,факс (85552) 3-44-14,E-mail:aktanysh@tatar.ru,www.aktanysh.tatarstan.ru

«Җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тәкъдимнәре нигезендә, Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының 2014 елның 17 апрелендәге ПР-220 номерлы карары белән расланган җир кишәрлегенең шәһәр төзелеше планын әзерләү һәм бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентының 2 өлешенең 2.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәрешләр кертергә.

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Хезмәт күрсәтү вакыты, шул исәптән хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, хезмәт күрсәтүне туктатып тору вакыты, әгәр РФ законнарында каралган булса, | Рөхсәт бирү - гаризаны теркәгәннән соң 14 эш көненнән дә артмый<br>Җир кишәрлегенең элек расланган шәһәр төзелеше планы дубликатын бирү гариза кергән вакыттан алып 4 көн эчендә, әмма 10 календарь көннән дә артык булмаган вакытта башкарыла. | РФ грк 6ст. 57.3 |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Актаныш муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Актаныш муниципаль районы комитеты җитәкчесенең экономика буенча урынбасары Л.Р. Сираевага йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Э.Н. Фәттахов